ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 032 от «07» 05 2020 г.

Район Башлыгының 2015 елның
3 июнендә кабул ителгән
049 нчы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә,
к а р а р б и р ә м:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге 049 нчы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле затлар билгеләү исемлеген, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.17 статьясы буенча беркетмәләр төзүне өстәп, тулыландырырга (кушымта нигезендә).

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

000039

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының
07.05.2020 ел, 032 нчы
карарына кушымта

| статьяның номеры | статьяның эчтәлеге | җирле үзидарәнең беркетмә төзү вәкаләте йөкләнгән органы | Вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 2.17. статьясы | Татарстан Республикасының яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) кисәтүгә һәм аның таралыш нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар таләпләрен үтәмәү | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты | - Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең (социаль мәсьәләләр буенча урынбасары);<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының хокук эше бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча);<br>-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокук эше бүлеге әйдәп баручы белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану инспекторы),<br>- Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы;<br>- Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече |

Муниципаль район Советы
аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизов